СОВЕТ СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с. Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

“14” нче декабрь 2022 ел. — № 3-21

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 5 июнендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә хакында» 1-31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2018 елның 5 июнендәге 1-31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә (алаг таба –Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гавами тыңлауларны үткәрү вакытын һәм урынын билгеләү турындагы мәгълүмат, шулай ук гавами тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты гавами тыңлаулар үткәрү көненә кадәр 7 көннән(*календарь көннәрдә*) дә соңга калмыйча басма массакүләм мәгълүмат чараларында, информацион стендларда, Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Бердәм портал) урнаштырылырга тиеш.

Бердәм порталда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы халкына хәбәр итү максатларында гавами тыңлаулар билгеләү һәм

муниципаль норматив хокукый акт проекты турында мәгълүмат урнаштыру гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органының вәкаләтле хезмәткәре тарафыннан җирле үзидарә органының гавами тыңлаулар әзерләүне һәм уздыруның шәхси кабинетыннан файдаланып, Бердәм порталның кире элемтә платформасының тиешле бүлегендә (алга таба - органның шәхси кабинеты) әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла».

1.2. Нигезләмәнең 6 статьясындагы 1.1 өлешенең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларны нигезләүне дә кертеп, басма массакүләм мәгълүмат чараларында, информацион стендларда бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) яисә Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адрес буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында, гавами тыңлаулар үткәргән көннән 5 көн эчендә урнаштырылырга тиеш.».

1.3. 7 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 4.1 өлеш өстәргә:

«4.1 Гавами тыңлауларда катнашучылар муниципаль норматив хокукый актның гавами тыңлауларга чыгарылган проекты буенча «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

Муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча фикер алышуга чыгарылган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр авыл җирлеге халкы тарафыннан, авторизациядән соң, бердәм портал кулланып, «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификациянең бердәм системасы» ярдәмендә кертелә».

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертү гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын һәм гавами тыңлауларны билгеләү турында мәгълүматны бастырып чыгару көненнән башлана һәм гавами тыңлаулар уздыру көненә кадәр 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Авыл җирлегендә яшәүчеләр муниципаль норматив хокукый акт проекты буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керткәндә шулай ук үзләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), гражданның шәхесен таныклаучы төп документның реквизитлары, туу датасы һәм яшәү урыны буенча теркәлү адресы турында белешмәләрне дә җибәрәләр.

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәр органның шәхси кабинетына җибәрелә.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге башлыгы,
Соколка авыл җирлеге Советы рәисе И.Р. Сафин